РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Ул.Центральная, д.46, с.Бизяки, Менделеевский район, Республика Татарстан, 423648

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк урам, 46 йорт, Бәзәкә авылы, Менделеевск районы, Татарстан Республикасы,423648

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 8 09.11.2024 ел

Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлегенең
Бәзәкә авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 21 ноябре 10.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2024 елның 21 ноябре 13.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2024 елның 21 ноябре 16.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Бәзәкә авыл җирлеге җыеннарының барлык этапларын уздыру урыны адреслар буенча:

Беренче этап: Бәзәкә авылы, Яңа урам, 1 й., авыл мәдәният йорты
Икенче этап: Бәзәкә авылы, Үзәк урам, 46 й., административ бина
Өченче этап: Бәзәкә авылы Яр Буе урамы

5. Бәзәкә авылында яшәүчеләр исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Яшьләр ур., 1-126 й., Елга аръягы ур.,1-106 й. Яңа ур., 1-36 й
Икенче этап: Үзәк ур., 1-102 й.
Өченче этап: Яр Буе ур. 1-36 й. Дуслык ур., 1-14 й., Бакча ур., 1-11 й., Рифкат Таҗиев ур., 4,7 й. Урман ур., 10 й.

6. «2025 елда Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән , югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан бер тапкыр түләүне 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга.

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Бәзәкә авылында Бәзәкә елгасы аша күперләрне ремонтлау).

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;(ташып вак таш сатып алу, вак ташны тигезләү, Бәзәкә авылындагы юлларны кардан чистарту, Беларус 82.1 тракторы өчен кар чистарткыч сатып алу. үткән елларның калган өлешен юлларны кардан чистартуга юнәлтергә).

3. Урамнарны яктырту җайланмасы - яктырткычлар сатып алу). Бәзәкә авылында урамнарны яктырту җайланмасы).

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Бәзәкә авылында Беларус 82.1 тракторына фронталь төягеч сатып алу, Беларус 82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу, механизаторга хезмәт хакы түләү), бензин триммерлары сатып алу, үлән чабу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү, агачларны кисү, территорияне төзекләндерү, балалар спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү өчен экскаватор хезмәтләре күрсәтү).

5. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын буяу өчен буяу сатып алу).

6. Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (суга батыру насослары сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә Бәзәкә авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы ________________ И.И.Кәшәфетдинов
(имза) (имзаның аңлатмасы)